ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 12 2021 г. № 1017

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 мартындагы 248 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының Милли рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасының инвестицион климат торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 21 октябрендәге 991 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 мартындагы 248 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» 2 бүлегендәге «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6 пунктның 4 пунктчасына, 5 пунктчасына «(челтәр оешмалары башкара торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру очракларыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

- «Административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре» 3 бүлегендәге 3.3.3 пунктчасына һәм 3.5.1 пунктчасының 4 абзацына «(челтәр оешмалары башкара торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру очракларыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

- административ регламентның 3 нче кушымтасындагы ОРДЕРДА һәм ОРДЕР КӘГАЗЕНДӘ булган «Ордерда күрсәтелгән эшләр кызыксынган оешмалар белән килештерелгән» 8 нче пунктына «челтәр оешмалары тарафыннан башкарыла торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтырганда КИЛЕШТЕРҮ ТАЛӘП ИТЕЛМИ» сүзләрен өстәргә;

- административ регламентның 4 нче кушымтасына «җир эшләрен башкаруга РӨХСӘТ» сүзләреннән соң «(челтәр оешмалары башкара торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру очракларыннан тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Х.Муллин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874